ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) социаль хезмәт күрсәтү йорты, шул исәптән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү йорты;»;

2) 8 статьяның 8 өлешендәге 6 пунктында «психик тайпылышлары булган гражданнар, шул исәптән психик тайпылышлары булган балалар өчен интернат йортларда» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү йортларында, шул исәптән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү йортларында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 88-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ